ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е                К А Р А Р

«08» июль 2019 ел                №952

Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турында Кодексының 20.25 статьясы буенча административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затны раслау турында

«Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 18 июлендәге 225-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм «Башкарма производство турында»гы Федераль закон нигезендә, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты административ комиссиясе тарафыннан тартылган административ җәзаны башкарудан баш тарткан затларга карата РФ Административ хокук бозулар Кодексы буенча административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле зат итеп, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты административ комиссиясе рәисе Мөхәмәтшин Артур Айдар улын билгеләргә.

2. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип таныргa:

2012 елның 27 ноябрендәге 619 нчы номерлы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының административ комиссиясе рәисенә административ комиссия тарафыннан салынган штраф түләмәгән затларга карата административ хокук бозу турында беркетмәләр төзү хокукын бирү турында»;

2015 елның 25 декабрендәге 1404 нче номерлы «Татарстан Республикасы» Лениногорск муниципаль районы " муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты административ комиссиясе рәисенә 20.25 статья буенча беркетмәләр төзү вәкаләтләрен бирү турында»;

2016 елның 19 апрелендәге 611нче номерлы «Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турында кодексының 20.25 статьясы буенча административ хокук бозу турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затны раслау хакында».

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында бастырырга.

4.Әлеге карарны контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы З.Г. Михайлова

Е.А.Ненад
5-46-72